**ГЛАВА**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2023 елның 3 нче ноябре — № 9

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге бюджеты проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында»

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы 2019 елның 15 ноябре 50-166 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә», Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 декабре 17-61 нчы номерлы карары белән расланга “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә» нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең бюджеты проектын тикшерүдә катнашу өчен хокукларын саклау максатларында карар бирәм:

1. 2023 елның 22 ноябрендә 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 йортта урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советы бинасында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге карары проекты буенча халык алдында тыңлаулар уздырырга.

Гавами тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 2021 елның 28 декабрендәге 17-61 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 2022 елның 12 нче гыйнварендә басылып чыккан «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә» нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты секретаренә «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025, 2026 елдагы план чорына бюджеты турында» карары проектын җәмәгать тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге Советы утырышында 12.12.2023 елга кадәр карап тикшерүгә кертергә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча Комиссия рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Яңа Чишмә
авыл җирлеге Башлыгы В.М.Козлов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгының 2023 елның 3 нче ноябре 9 нчы номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының «2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге бюджеты турында» карары проектына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 елларның планлы чорына бюджеты проектына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертергә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 нче йорт, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибенә язма формада.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә: httr://pravo.tatarstan.ru бастырылганнан соң.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 нче йорт адресы буенча (конвертта «бюджет турында фикер алышу» тамгасы белән) бирелә.